Газета МБОУ «АСОШ №2»



# Пульс школы
# Мәктәп пульсы

## С днём народного единства!

№ 3
Ноябрь, 2023 г.




Поздравляем вас с Днем народного единства! Этот праздник символизирует идею национального согласия и сплочения общества, в котором все мы, граждане России разных национальностей и убеждений, являемся одним народом с общим историческим прошлым. В единстве и сплоченности — наша сила и залог достойного будущего!

Сезне Халыклар бердәмлеге көне белән котлыйбыз! Бу бәйрәм җәмгыятьнең милли татулык һәм берләшү идеясен гәүдәләндерә, без барыбыз да, төрле милләт һәм дин кешеләре, уртак тарихи үткәннәр белән бер халык булып торабыз. Бердәмлектә һәм бердәмлектә - безнең көч һәм лаеклы киләчәкнең нигезе!

**В этом выпуске:**


| | |
|---|---|
| Мин Арча баласы! | 2 |
| С Днём матери! | 4 |
| Из школьной жизни… | 5 |

# Мин Арча баласы!

Сишәмбе эш башларга ярамый диләрме әле, ә минем өчен бу көн атнаның иң уңышлы көне. Бу юлы да шулай булды. Директорыбыз Гөлназ Гиниатуллина "Мин Арча баласы" бәйгесе турында әйтүгә эшкә керештек. Шул минутта ук каршыма очраган Камилә белән Зөһрәгә: "Кызлар, иртәгә кадәр команда җыярга кирәк", - дим. Алардан бары киңәш көтәм, чөнки 11 ләрне борчырга уңайсыз бит. Алар бертавыштан: "Безнең катнашасы килә", - димәсеннәрме. Эчкә җылы керде. Сөйләшеп торганда, яныбызга мәктәпнең тәрбия эше буенча директор киңәшчесе Лилия Сәйфетдинова да килеп җитте. Тиз генә тәрбия эше буенча завучыбыз Гөлназ Зиновьева янына ашыктык (5 минуттан дәрескә керәсе). Ул безгә "Нур" балалар телерадиостудиясенә йөрүче Самира белән Камиләне тәкъдим итте. Аларны эзләп табуы авыр булмады, тик менә иртәгә олимпиада икән бит әле (11нчедәге Камиләнеке дә). Аллаһ рәхмәте беләндер, ризалашты бит бу кызларыбыз да. Инде җиң сызганып эшкә керештек. Уңган, булган кызларыбыз эшне тиз арада бүлешеп тә өлгерде. Иң беренче эш итеп нинди дә булса тарихи бина сайларга кирәк иде. Лилия апалары мәктәбебез тарихын яктырту ничек булыр ди, Коммуна урамы тарихына тукталыйк диген тәкъдим дә булды. Бу юлы мәктәп тарихын сайларга булдык. Берсебездә дә дәрес кайгысы калмаса да, киләсе тәнәфестә җыелабыз дип, дәрескә таралыштык. Бу дәрес бетешкә һәрберебездә инде кызыклы идеяләр туган иде. Тиз генә төркем булдырып, "Телеграмм" да онлайн аралашу башланды. Бер тәүлек дигәндә инде проект әзер иде. Кызу тотты кызлар эшне ( әле бит район олимпиадасы да бар). Форум көне дә килеп җитте. Әле бу көнне дә эшлисе эшләр калган икән. Иртүк килеп, мәктәптә эшләрен тәмамлап, тугызнчы яртыда кызлар инде Мәдәният йортында иделәр. 20 команда арасында көч сынашу ничек булганын сөйләр өчен кызларның үзләренә сүз бирик.




Камилә Абдрахманова:

- Форумда бик көчле командалар җыелды. Һәр мәктәп яктырту өчен кызыклы темалар сайлады: Казанка елгасы, Яңа Чуриле авылы, Колачы авылы һәм башкалар. Арча районының истәлекле урыннар исемнәре янгырады. Барыбыз да 4 сәгать фильм өстендә эшләдек: вакытның яртысы мастер-классларга бүленде, икенче өлеше мөстакыйль эшкә багышланды. Без үзебезнең мәктәп турында проект ясадык. Тарих укытучыларыннан сораштык, мәктәп музееннан мәгълүмат алдык. Бергәләшеп эшләгәч, барысы да әйбәт чыкты. Видеопрезентация һәм сценарий әзер булды. Проектны яклаганда безгә мәктәп тарихы буенча сораулар да бирделәр. Җавапны белмәсәк тә, бик күп кызыклы, яңа информация белдек. Бүләкләү вакыты да килеп җитте. Без — Медиафорумның җинүчеләре! Һәм "Мин Арча баласы" проектының 5нче сезонында безнең мәктәп турында ролик төшереләчәк. Мин бу нәтиҗәгә чиксез шат!

Камиля Гарифҗанова:

- Без башкарырга тиешле эш күләмле булуга карамастан, чара минем өчен бик кызыклы булды. Журналистика белән кызыксынганга, мин сценарий осталыгы буенча мастер-класста катнашырга теләдем. Аны журналист Шәрипов Рузәл алып барды. Ул безнең мәктәпне тәмамлаган иң мактаулы укучы, аны барлык активистлар беләләр һәм аннан үрнәк алалар. Мин Рузәлне күрергә бик шат идем.Ул чыннан да яхшы киңәшләр бирде, сценарийны ничек яхшырак төзергә икәнен аңлатты. Осталык дәресеннәе соң мин алдан язылган сценарийда бик күп хаталар барлыгын аңладым, шуңа күрә тиз темпта аны төзәтә башладым.Әлбәттә, кызларның ярдәме дә кирәк булды, аларның миңа караганда да тәҗрибәсе күбрәк, чөнки алар актив рәвештә журналистлык эшчәнлеге белән шөгыльләнәләр. Сценарийны язганнан соң, Камиләгә бер сәгать эчендә видео ясарга кирәк булды. Аның өчен бу бөтенләй авыр эш түгел иде. Әмма бу каршылыкларсыз булмды.Проектларны яклау башланганда, безнең видео әле жюрига бирелмәгән дә иде. Жирәбә буенча унтугызынчы булып чыгыш ясарга туры килүе хәерлегә булды. Укуча Загриева Ләйлә эшләве дә әйбәт булды . Ул безгә видеоны флешкага күчерергә ярдәм итте. Шуннан соң без тыныч кына үз чиратыбызны көттек. Чыгыш алдыннан җиңелчә курку да булды, әмма шулкадәр озак көтү аны бөтенләй юкка чыгарды. Инде жюри каршына басабып башлыйбыз: "Исәнмесез, без Арча баласы!". Чыгыш вакыты бик тиз үтте. Безгә: "Сез зур эш башкаргансыз, тарихи фактларны күтәргәнсез, молодцы. Сезгә шундый сорау: Сезнең мәктәп



ишегалдында кемгә багышланган һәйкәл тора?" Әллә ни арада кулыма микрофон килеп керде: "Ленин бабайга" дип җавабымны бирдем дә якякка карыйм. Көлешәләр. Дөрес әйтмәдем ахрысы дигән уй үтте баштан. Йә Аллаһ, "Афәрин" дип кул чаптылар. Булды бу. Безгә катнашучылар грамотасын һәм кружкалар бирәләр. Без китәбез. "Без чыгыш ясадык? Ничек инде?" -сораулар башыта әйләнә. Урыныма утырам да, хәзер генә барысын да аңлыйм: "Без чыгыш ясадык !"Соңгы команда чыгыш ясый, 10 минут үтә, җиңүчеләрне игълан итү башлана. Сулыш алуны тоткарлый, берничә мәктәпне атыйлар, басым тагын кискенләшә һәм ... : "Җиңүче дипломы, 5 мең сумлык сертификат белән "Арча урта гомуми белем бирү мәктәбе 2" бүләкләнә!" Шатлык, зур шатлык безнең җаныбызда. Грамота, сертификат, сувенир тәлинкә тапшыралар, хәтер өчен берничә фото ясылар һәм ниһаять җиңеллек белән сулый башлыйм. Без булдырдык!



Зөһрә Мусина:

- Ноябрьнең соңгы көне безнең өчен уңышлы булды. Әлеге проектта чыгыш ясап җиңүчеләр рәтендә булу - зур куаныч. Мин 3 нче сезонда да катнашкан идем. Шунысы бераз моңсу: безнең өчен 4 нче сезон - соңгысы. Ябылу тантасы шәп оештырылды. Бу көнне безгә бүләк ителгән "мин арча баласы"дигән логотиплы футболка, блакнот, ручкаларны истәлеккә саклрбыз, мөгаен. "Безнең тарих төрле мәгълүматларда" мәйданчыгын Ленар Гобәйдуллин алып барды. Без аннан күп нәрсәгә өйрәндек. Тагын "Актерлык остаханәсе", Сценарийй язу серләренә өйрәтүче остаханә мәйданчыгын алып барды. Һәрбер осталык дәресе бик файдалы һәм кызыклы үтте.

Әзерләнергә бирелгән 2 сәгать вакыт бик тиз үтте. Чыгыш ясау вакыты якынайганда дулкынлана башласак та, бер-беребезне: "борчылма, барысы да яхшы була" дип тынычландырырга көч таптык. Чыннан да, ярты сәгать кала мин инде тыныч идем кебек, ә кызлар әле дә борчылалар икән әле. Ниһаять көтелгән минут та җитте. Чыгыш тәмам.10 минуттан бүләкләү тантанасы. Укытучыбыз Рәсимә Ибраева да килеп җитте. Бергәләп борчыла башладык. Командыбызның уңышлы чыгышын инде бәяләүчеләр дә бар, бәлки 10лыкка керербез дигән уй барыбызгы да Җиңүчеләр рәтендә бишенче итеп безнең мәктәпне атаганда куанычтан башлар әйләнеп китте хәтта. 2 көн эчендә бик зур эш эшләнде. Командабыз белән бик тату эшләдек, дуслаштык. Безгә ышаныч белдергәннәре, ярдәм иткәннәре өчен җитәкчеләребезгә бик зур рәхмәт.

Булачак һөнәрем журналистика белән бәйле булмаса да, мин бу форумнан бик күп тәҗрибә алдым.




Лилия Сәгъдиева:

- Хәзерге вакытта яшьләр өчен бик матур һәм кызыклы чаралар күп үткәрелә. Аеруча Туган якны, аның тарихын өйрәнүгә, патриотик хисләрне торгызуга басым ясала, бу, әлбәттә бик сөенечле хәл.

Шундый чараларнын берсе - елдан-ел популярлык яулаучы "Мин Арча баласы" проекты.

Әлеге проект кысаларында уздырылган медиа-фестивальдә катнашу мөмкинлеген без дә кулдан ычкындырмаска булдык. Мәктәпнең иң акыллы, талантлы, иң булган кызларыннан команда җыйдык һәм тиз генә катнашу турында гариза да бирдек.

Командабыз шул көннән үк эшкә кереште. Аларның тарихи бина итеп үзебезнең мәктәпне сайлауларына куандык. Белем йортыбыз турында булган барлык кызыклы тарихи мәгълуматларны туплап, шул арада видео да төшереп алдылар. Кыскасы, бөтенебезне аякка бастырдылар!

Иң куандырганы шул: тырышлыклары юкка китмәде. Кызларыбыз беренче унлыкта - җиңүчеләр рәтендә! Бу хәбәр барыбызны да бик куандырды, чөнки киләсе елның гыйнвар аенда безнең мәктәп турында видеоролик төшерәчәкләр.

Район күләмендә мәктәп данын яклаган кызларыбызга алга таба да уңышлар телибез, яңаданяңа үрләр яуларга насыйп булсын! Афәрин!

*Сәхифәне "Яшь журналист" түгәрәге җитәкчесе Рәсимә Ибраева әзерләде.*

# С Днём матери!

«... Мы любим сестру, и жену, и отца, но в муках мы мать вспоминаем...» Эти точные строчки лишний раз доказывают, что жизнь каждого из нас начинается на руках матери, которая становится самым близким и родным человеком. Традиция праздника берет начало из мистерий древнего Рима, где почитали Великую Марию — богиню, мать богов. Каждая страна имеет свою дату празднования. По Указу Б. Н. Ельцина Президента РФ в 1998 году в России днем матери считается последнее ноябрьское воскресенье. Этот праздник необходим, чтобы показать значимость, истинное предназначение женщины. Они хранят уют и тепло в доме, заботятся о своем чаде, нося его под сердцем, поддерживают, оберегают на протяжении всей жизни. В этот день принимают свои поздравления как уже состоявшиеся, так и готовившиеся к получению столь высокого звания, беременные дамы. Мамы и бабушки получают цветы, подарки, поздравления от всех близких и родных.
Во многих семьях стало доброй традицией готовить праздничный стол, устраивать вечерние посиделки.





Активисты Совета Первых присоединились ко Всероссийской акции, приуроченная к празднованию Дню Матери #ЛЮБИМОЙ_МАМЕ. Приготовили завтрак для мамы.

Спасибо тебе, мама,
За поддержку, любовь и тепло,
За то, что всегда прощала
И никогда не держала зло.

Спасибо тебе, мама,
За нежность и доброту,
За то, что ты всегда знала,
Какое мороженое люблю.

Спасибо тебе, мама,
За помощь и советы твои,
За то, что я всю жизнь утопала
В уюте, огромной семейной любви.

Хочу тебя я поздравить
И от всей души пожелать
Вместе нам почаще смеяться,
Наслаждаться временем и мечтать.

Тебе я желаю здоровья,
Терпения и неземной красоты,
Хочу, чтоб душа твоя пела,
В руках всегда были цветы.

Хочу, чтоб себя ты ценила,
Себя всегда берегла,
Чтоб добротой сердца ты пленила,
И словно роза цвела.

Будь счастлива, моя мама,
Пусть беды тебе ни по чем,
Знай, ты лучшая самая,
Такой, как ты, не сыщешь с огнем!

**Поздравляем, дорогие мамы!**

# Из школьной жизни...

8 ноября 2023 года активисты антинаркотического проекта «SaMoStoятельные дети», ученики 7А класса отряда «RISk» МБОУ «Арская СОШ №2» г. Арск провели республиканскую акцию «Здоровая мама - здоровый ребёнок!», посвященную Всероссийскому дню матери.




9 ноября на базе МБОУ "Арская СОШ 7" прошел зональный тур соревнований муниципального этапа Чемпионата Школьной баскетбольной лиги «КЭС-БАСКЕТ» среди сборных команд образовательных организаций сезона 2023-2024 Арского муниципального района. По итогам соревнований наша команда девушек и юношей заняла 2 место!





В МБОУ «Арская СОШ №2» 10 ноября состоялась торжественная церемония посвящения обучающихся 1-3 классов в ряды «Орлята России», которые являются первой ступенью Российского движения детей и молодёжи «Движение первых».



16 ноября в МБОУ «Арская СОШ №2» прошло общешкольное родительское собрание, темой которого было: Семья и школа ; взгляд в одном направлении собрание.

Директор школы Гиниатуллина Г.Г. познакомил родителей с образовательной деятельностью школы за первую четверть. Напомнил о правах и обязанностях учащихся и их родителей.

С обновлениями системы воспитания и с вызовами 2023-2024 года, с нововведениями, касающимися профориентации, ознакомила Зиновьева Г.Г., заместитель директора по воспитательной работе.

С программой развития социальной активности обучающихся начальных классов «Орлята России» и предстоящими планами детского движения подробно остановилась Сагдиева Л.Т., советник директора по воспитанию и взаимодействию с детскими общественными объединениями.

Таким образом, общешкольное родительское собрание имело большое значение для всех участников образовательного процесса. Родители получили информацию о текущих достижениях и планах школы, а также смогли обсудить важные вопросы с педагогами и администрацией.



# Из школьной жизни...

13 ноября - Всемирный день доброты!

Этот праздник был учрежден в 1998 году. Идея праздника принадлежит японскому доктору Мичико Катори. Она решила, что мир нуждается в таком дне, который бы напоминал людям о важности доброты и сострадания в нашей жизни

С тех пор каждый год 13 ноября мы обмениваемся улыбками и помогаем тем, кто рядом с нами. Ведь доброта - это не только слова, но и дела. Улыбка, комплимент или поддержка в трудную минуту - всё это проявление доброты. И такие простые жесты могут сделать нашу жизнь и мир вокруг нас лучше.

Школьное ученическое самоуправление оформили стенд и интерактивную доску, где ученики могли оставлять свои послания своим одноклассникам и учителям.

Важно помнить, что доброта всегда возвращается, а мир становится светлее благодаря нашим добрым делам и поступкам.



17 ноября прошёл районный фестиваль-конкурс английской песни "We are the world".
В номинации «Сольное исполнение» ученица 6В класса Фархуллина Сафина заняла 1 место, руководитель Валиуллина Р.Г. ученица 2А класса Кадырова Диана заняла 1 место, руководитель Сагдиева Л.Т. ученицы 3А класса Фархуллина Амина, Фатыхова Дина заняли 3 место, руководитель Сагдиева Л.Т.

Молодцы, поздравляем!




19 ноября в Фиджитал-турнире, который состоялся в Арском спортивном комплексе АРЧА, объявили победителей конкурса ребусов.

Победителей поздравили и наградили Помощник Раиса РТ, руководитель регионального отделения Российского движения детей и молодежи «Движение первых» в Татарстане Тимур Джавдетович Сулейманов и Глава Арского муниципального района Ильшат Габдельфартович Нуриев.

Ученики из нашей школы так же стали победителями. Это Кадырова Диана, ученица 2А класса, Шакиров Амир, ученик 1Б класса, Шакиров Айзат, ученик 6Б класса.

Поздравляем!




**_Редактор_** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
**_Дизайнер - верстальщик_** Гузелия Фаттахова
**_Фотокорреспондент_** Алина Магсумова
**_Корректор_** Гузелия Фаттахова
**_Редколлегия_** Камилла Мифтахова

**_Адрес:_** ул. Мостовая, дом 15
**_Сайт школы:_** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2